СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 11 » декабрь 2019 ел** **№ 293**

**«Арча муниципаль районы Советы Регламенты турында» Арча район Советының 2005 елның 28 декабрендәге 26 номерлы карары (11.11.2009 ел, №269, 26.06.2010 ел, №299, 17.02.2014 ел, №249 үзгәрешләр белән) белән расланган Арча район Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

Арча муниципаль районы Уставы нигезендә Арча район Советы **карар бирде**:

1. «Арча муниципаль районы Советы Регламенты турында» Арча район Советының 2005 елның 28 декабрендәге 26 номерлы карары **(11.11.2009 ел, №269, 26.06.2010 ел, №299, 17.02.2014 ел, №249 үзгәрешләр белән)** белән расланган Арча район Советы Регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә һәм аны кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар Рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм “Интернет” челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk/tatarstan.ru) халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча муниципаль районы башлыгы урынбасары, район Советы рәисе урынбасары Г.Ф. Гариповага йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г.Нуриев

**Арча район Советының**
**2019 елның “11” декабрь**
**29 номерлы карары белән**
**РАСЛАНГАН**

# АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ РЕГЛАМЕНТЫ

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

### 1 статья

Әлеге Регламент федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Арча муниципаль районы Уставы (алга таба – Район Уставы) нигезендә Арча район Советының (алга таба – Район Советы) эшчәнлек тәртибен билгели.

### 2 статья

Район Советы эшчәнлеге күмәк, ирекле һәм эшлекле фикер алышу һәм мәсьәләләрне хәл итү, хәбәрдарлык, законлылык, Район Советы һәм муниципаль район Башкарма комитеты (алга таба – Район Башкарма комитеты) компетенцияләрен чикләү, муниципаль район халкы алдында җаваплылык һәм хисап тоту нигезендә башкарыла.

### 3 статья

1. Район Советы эшенең төп формасы булып аның утырышы тора.
2. Район Советы утырышы ачык һәм хәбәрдарлык рәвешендә үткәрелә.
3. Район Советы ябык утырыш үткәрү турында карар кабул итәргә мөмкин. Әлеге утырышның кирәклеге турында фикер алышулар булырга мөмкин.

### 4 статья

Район Советы утырышларында мәсьәләләрне алдан карау һәм аларны карауга әзерләү, утырышлар арасында депутатларның эшен оештыру өчен Район Советы даими комиссияләр төзи.

### 5 статья

Район Советы, аның комитетлары һәм комиссияләре, Район Советы депутатлары, муниципаль район Башлыгы-Район Советы рәисе (алга таба - Район Башлыгы) һәм аның урынбасары эшчәнлеген хокукый, оештыру ягыннан, документаль, мәгълүмати, матди-техник яктан тәэмин итү Район Советы аппараты тарафыннан Район Советы аппараты турында Нигезләмә нигезендә башкарыла.

## 2 бүлек. Район Советы Депутаты

### 6 статья

1. Район Советы депутаты эшчәнлеге формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) Район Советы утырышларында катнашу;

2) Район Советының даими комиссиясе эшендә катнашу;

3) муниципаль район карамагындагы мәсьәләләр буенча оештыру-хокукый формаларына, иҗтимагый берләшмәләргә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларына, оешма җитәкчеләренә мөрәҗәгать итү;

4) норматив хокукый акт проекты кертү;

5) депутат таләбе кертү;

6) Район Советы тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актлар проектларын эшләүдә катнашу;

7) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә Район Советы тарафыннан кертелә торган Татарстан Республикасы законнары проектларын эшләүдә катнашу;

8) Район халкы белән очрашулар, аларның мөрәҗәгатьләре белән эшләү, вәкиле булган җирлек халкына үз эшчәнлеге һәм Районның җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү;

9) җирле референдумнарны, ачык тыңлауларны, җыелышларны, конференцияләрне һәм гражданнарны сораштыру үткәрүне оештыруда һәм үткәрүдә катнашу;

10) территориаль иҗтимагый үзидарәне оештыруда катнашу.

2. Район Советы депутаты үз эшчәнлеген федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм Район Уставында каралган башка рәвешләрдә дә башкара ала.

### 7 статья

1. Район Советы депутаты  Район Советы һәм аның президиумы, әгъза булып торган даими комиссияләрдә каралган барлык мәсьәләләр буенча хәлиткеч тавыш бирү хокукыннан файдалана.

2. Депутат Район Советының, аның президиумының, әгъза булып торган даими комиссиясенең барлык утырышларында да катнашырга тиеш.

3. Район Советының, аның президиумының, әгъза булып торган даими комиссиясенең барлык утырышларында катнаша алмаганда, депутат бу хакта Район Советына, президиум рәисенә, даими комиссиягә яки секретариатка алдан хәбәр итә.

4. Депутат түбәндәге хокукларга ия:

1) Президиумга, даими комиссияләргә һәм Район Советында тиешле вазыйфаларга сайларга һәм сайланырга;

2) Район Советына карау өчен сораулар тәкъдим итәргә;

3) Район Советы тарафыннан булдырыла торган органнар һәм Район Советы тарафыннан сайланучы (билгеләнүче, килештерелүче) вазыйфаи затлар кандидатураларын формалаштыру мәсьәләләре буенча фикер әйтергә;

4) хокук чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә Район Советы хокукый актлар проектларын кертергә;

5) Район Советы карарлары проектларына төзәтмәләр, көн тәртибе, тикшерелә торган сорауларның асылы һәм карау тәртибе буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә;

6) Район Советына хисап бирергә тиешле яки контрольлегендә булган теләсә кайсы органның яки вазыйфаи затның Район Советы утырышында чираттан тыш хисабын яки мәгълүматын тыңлау буенча тәкъдимнәр кертергә;

7) әлеге Регламентта билгеләнгән тәртиптә фикер алышуларда катнашырга;

8) үз тәкъдимнәрен нигезләп һәм тавыш бирү мотивлары буенча чыгыш ясарга, белешмәләр бирергә;

9) Район Советы утырышларында аның фикеренчә иҗтимагый әһәмияткә ия булган гражданнар мөрәҗәгатьләрен игълан итәргә.

10) Район Советы тарафыннан булдырыла торган органнар һәм Район Советы тарафыннан сайланучы (билгеләнүче, килештерелүче) вазыйфаи затлар кандидатуралары шәхси составы турында фикер әйтергә;

11) Район Советы утырышларының аудиоязмасы һәм беркетмәләре белән танышырга.

5. Район Советы утырышында депутат тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр Район Советы карары проектын эшләгәндә Район Советының тиешле даими комиссиясе тарафыннан карала һәм фикер алышына.

**8 статья**

Район Советы депутаты законнар, муниципаль район Уставы һәм әлеге Регламент белән билгеләнгән башка хокуклардан файдалана.

**9 статья**

Район Советы депутаты Район халкыннан кергән мөрәҗәгатьләрне, гаризаларны һәм шикаятьләрне карый, үз вәкаләтләре чикләрендә булган мәсьәләләрне дөрес, үз вакытында хәл итәргә ярдәм итә, гражданнарны кабул итә, җәмәгатьчелек фикерен өйрәнә, тиешле җирле үзидарә органнарына, кирәк булганда дәүләт һәм иҗтимагый органнарга тәкъдимнәр кертә.

**10 статья**

Район Советы депутатына җирлектәге вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен әлеге җирлектә яшәүчеләр белән очрашуларны оештыруда Район Башлыгы ярдәм итә.

**11 статья**

Район Советы депутаты, очрашулар вакытында вәкиле булып торган авыл халкына, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары аша үз эшчәнлекләре турында мәгълүмат бирә.

## 3 бүлек. Район Башлыгы. Район Башлыгы урынбасары

**12 статья**

Район Башлыгы Район Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча:

1) Район Советы эшен оештыра, Район Советы утырышларын чакыра һәм аларга рәислек итә;

2) дәүләт хакимиятенең федераль органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә Район Советы исеменнән эш алып бара;

3) Район Советы депутатларына үз вәкаләтләрен тормышка ашыруда ярдәм күрсәтә;

4) Район Советы президиумы һәм даими комиссияләре эшчәнлеген координацияли;

5) Район Советының даими комиссияләренә йөкләмәләр бирә;

6) Район Советы эшенең хәбәрдарлыгын тәэмин итә;

7) Район Советы аппараты структурасын Район Советына раслауга кертә;

8) Район Советы аппараты эше белән җитәкчелек итә;

9) Район Советында гражданнарны кабул итә, аларның мөрәҗәгатьләрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карый;

10) Район Советы исеменнән судка җибәрелә торган документларга (шул исәптән дәгъва гаризаларына, ышаныч кәгазенә һәм башка документларга) кул куя;

11) федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Район Уставында һәм әлеге Регламентта каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**13 статья**

1. Район Башлыгы яңа сайланган Район Советының беренче утырышында Район Советы депутатлары арасыннан яшерен тавыш бирү юлы белән Район Советы вәкаләтләре вакытына сайлана.

2. Район Башлыгын сайлау Район Советы депутатлары тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар арасыннан, шул исәптән Район составына керүче җирлекләрнең вәкиллекле органнары, Район халкы, җәмәгать берләшмәләре, Татарстан Республикасы Президенты тәкъдимнәре нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Район Башлыгы вазыйфасына сайлануга тәкдим ителгән депутат үз кандидатурасын кире алуы турында белдерергә хокуклы.

**14 статья**

1. Район Башлыгы вазыйфасына сайлануга тәкдим ителгән барлык кандидатуралар буенча, үз кандидатурасын кире алулары турында белдерүчеләрдән тыш, фикер алышу үткәрелә . Фикер алышу барышында кандидатлар булачак эшчәнлек программасы белән чыгыш ясыйлар һәм депутатлар сорауларына җавап бирәләр. Һәр депутат тәкъдим ителгән программа турында үз фикерен әйтергә, тәкъдим ителгән кандидатура яклы яки каршы өндәргә хокуклы.

2. Район Башлыгы вазыйфасына тәкъдим ителгән кандидатуралар турында фикер алышканнан соң кандидатлар, үз кандидатурасын кире алулары турында белдерүчеләрдән тыш, яшерен тавыш бирү өчен бюллетеньгә кертелә. Һәр депутат бер кандидат өчен генә тавыш бирә ала.

3. Район Башлыгы вазыйфасына сайланган дип кандидат Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан тавыш бирү нәтиҗәсендә күпчелек тавыш җыйганда санала.

4. Әгәр Район Башлыгы вазыйфасына кандидатларның берсе дә сайлау өчен таләп ителә торган депутатлар тавышларын җыймаса, кандидатларның кабат тәкъдим ителүе уздырыла. Шул ук вакытта элегрәк тәкъдим ителгән кандидатларны тәкъдим итү рөхсәт ителә.

5. Әгәр Район Башлыгы вазыйфасына икедән күбрәк тәкъдим ителгән кандидатларның берсе дә сайлану өчен таләп ителә торган депутатлар тавышы санын җыймаса, Район Советының утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителгән карары буенча, иң күп тавыш җыйган ике кандидатура буенча икенче тур тавыш бирү үткәрелә. Әгәр тавыш бирүнең икенче турында Район Башлыгы сайланмаса, Район Башлыгы вазыйфасына тәкъдим итү процедурасы кабатлана.

**15 статья**

1. Район Башлыгы урынбасары Район Башлыгы тәкъдиме белән Район Советы депутатлары арасыннан сайлана.

2. Район Советы депутаты, әгәр аны сайлау өчен Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелеге тавыш бирсә, Район Башлыгы урынбасары вазыйфасына сайланган дип санала.

3. Район Башлыгы урынбасары муниципаль Район Башлыгының вәкаләте буенча аның аерым функцияләрен башкара һәм ул булмаганда яки үз вазыйфаларын башкара алмаган очракта Район Башлыгын алмаштыра.

4. Район Башлыгы урынбасарының вәкаләтләре муниципаль район Уставында каралган нигезләр буенча һәм тәртиптә вакытыннан алда туктатылырга мөмкин.

5. Район Башлыгы урынбасары теләсә кайсы вакытта Район Советы карары белән, Район Башлыгы инициативасы белән кабул ителгән яки Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән бер өлеше булган депутатлар төркеме таләбе буенча вазыйфасыннан алынырга мөмкин.

Район Башлыгы урынбасарын алу турында карар Район Советы депутатларыныңн билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

## 4 бүлек. Район Советы президиумы һәм даими комиссияләре

### 16 статья

1. Район Советы үз вәкаләтләре вакытына Район Советы карамагына караган мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен депутатлар арасыннан даими комиссияләр төзи.

2. Район Советының даими комиссиясе үз компетенциясендә каралган мәсьәләләр буенча:

1) Район Советы карары проекты буенча бәяләмә әзерли;

2) Район үсеше планнары һәм программалары проектларын, Район бюджетын эшләүдә катнаша, алар буенча үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен кертә;

3) Район Советы кушуы буенча, Район Башлыгы яки үз инициативасы белән даими комиссия эшчәнлеге өлкәсенә караган мәсьәләләрне әзерли, алар буенча Район Советының хокукый актлары проектларын әзерли;

4) үз компетенциясе кысаларында Район Советы хокукый актларының үтәлешен контрольдә тота, әлеге мәсьәләләр буенча тиешле органнар һәм җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары докладларын һәм хисапларын тыңлый;

5) Район Советы утырышында карау өчен документлар проектларын әзерли;

6) Район Уставында һәм әлеге Регламентта каралган башка вәкаләтләрне башкара.

### 17 статья

1. Район Советының даими комиссияләре даими комиссия рәисе һәм әгъзалары составында район Советы депутатлары тарафыннан сайлана.

2. Район Советы депутатларның 7дән ким һәм 11дән артык санда була алмаган даими комиссияләренең составы, Район Советы депутатлары тәкъдимнәрен исәпкә алып, яңа төзелгән Район Советының беренче утырышында билгеләнә.

3. Район Советының даими комиссияләрен сайлаганда тавыш бирү тулаем состав буенча үткәрелә.

4. Район Советының даими комиссияләре рәисләре, кагыйдә буларак, альтернатив нигездә сайлана. Даими комиссия рәисе вазыйфасына кандидатуралар аның утырышында алдан каралырга тиеш.

5. Район Советының даими комиссияләре комиссия әгъзалары арасыннан даими комиссия рәисе урынбасарын һәм секретарен сайлыйлар, аның кандидатурасын фикер алышу өчен комиссия рәисе кертә.

6. Район Советы депутаты Район Советының ике даими комиссиясе әгъзасы булып тора ала.

**18 статья**

1. Район Советының даими комиссиясе рәисе Район Советы утырышында күпчелек тавыш белән Район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан чыгып сайлана.

2. Район Советының даими комиссиясе рәисе:

1) даими комиссиясенең эшчәнлеген оештыруны тәэмин итә.

2) комиссия утырышының көн тәртибен һәм чакырылган затлар исемлеген төзи;

3) комиссия утырышларын алып бара;

4) Район Советының башка комиссияләре, Район Башлыгы, Район территориясендә урнашкан предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар, массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара мөнәсәбәтләрдә комиссия исеменнән эш алып бара;

5) комиссия карарларына имза куя;

6) әлеге Регламентта каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

**19 статья**

Район Башлыгы, Район Башлыгы урынбасары даими комиссияләр әгъзалары итеп сайлана алмый.

**20 статья**

1. Комиссия составының кимендә өчтән икесе катнашса, район Советының даими комиссиясе утырышы тулы хокуклы була.

2. Район Советы комиссиясе карары комитет әгъзаларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

3. Район Советының берничә комиссиясенең уртак утырышларын үткәргәндә карар һәр комиссия әгъзаларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

**21 статья**

Район Советының даими комиссияләре үз эшенә жирле үзидарә органнары, шул исәптән Район Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, дәүләт органнары, иҗтимагый оешмалар вәкилләрен, экспертлар, белгечләрне җәлеп итәргә хокуклы.

**22 статья**

Район Советының даими комиссиясе утырышында аның составына кермәгән Район Советы депутатлары да катнаша ала.

**23 статья**

1. Район Советы, кирәк булганда, вакытлы комиссияләр төзи ала.

2. Әлеге комиссиянең бурычлары, вәкаләтләре һәм эшчәнлек сроклары Район Советы тарафыннан аларны төзегәндә билгеләнә. Вакытлы комиссияләр депутатлар арасыннан рәис һәм әгъзалары составында Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән төзелә.

**24 статья**

1. Вакытлы комиссия эшенең нәтиҗәләре буенча Район Советына үзе төзелгән мәсьәләнең асылы буенча доклад ясый. Аерым фикере булган комиссия әгъзалары аны Район Советы утырышында игълан итәргә хокуклы. Район Советы вакытлы комиссия доклады буенча карар кабул итәргә мөмкин.

2. Вакытлы комиссия, үз эшчәнлеген үзенә йөкләнгән бурычларны үтәгәннән соң яисә Район Советы карары буенча вакытыннан алда туктатыла.

**25 статья**

1. Район Советы рәисе, аның урынбасары һәм даими комиссияләр рәисләре арасыннан Совет эшен оештыру, даими комиссияләр эшчәнлеген координацияләү, Район Советы карамагындагы мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен президиум төзи.

2. Район Советы Президиумы үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча:

1) район үсеше планнары һәм программалары проектларын эшләүдә катнаша.

2) Район Советы кушуы буенча, Район Башлыгы яки үз инициативасы белән президиум эшчәнлеге өлкәсенә караган мәсьәләләрне әзерли, алар буенча Район Советының хокукый актлары проектларын әзерли;

3) үз компетенциясе кысаларында Район Советы хокукый актлары үтәлешен контрольдә тота, әлеге мәсьәләләр буенча тиешле органнар һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының докладларын һәм хисапларын тыңлый;

4) Район Советы утырышында карау өчен документлар проектларын әзерли;

5) Район Советына яки Район Башлыгына җирле әһәмияттәге иң мөһим мәсьәләләр турында халыкка фикер алышуга чыгару яки ачык тыңлаулар билгеләү турында тәкъдимнәр белән мөрәҗәгать итә;

6) әлеге Регламентта каралган тәртиптә Район Советының чираттан тыш утырышын чакыру турында тәкъдимнәр кертә;

7) район Уставында һәм әлеге Регламентта каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

## 5 бүлек. Район Советының эш тәртибе

### 26 статья

1. Яңа чакырылыш Район Советы беренче утырышка Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе сайланганнан соң җиде көннән дә соңга калмыйча җыела. Яңа оешкан Район Советының беренче утырышын Район Башлыгы, ул булмаганда аның урынбасары чакыра һәм әзерли.

2. Район Башлыгы сайланганчы, яңа оешкан Район Советының беренче утырышын яшь буенча иң өлкән Район Советы депутаты ача һәм алып бара.

### 27 статья

1. Район Советының чираттагы утырышлары кирәк булган саен үткәрелә, әмма кварталга кимендә бер тапкыр һәм Район Башлыгы тарафыннан чакырыла. Җәйге чорда утырышлар арасындагы тәнәфесләр озак булырга мөмкин. Чираттан тыш утырышлар Район Башлыгы тарафыннан үз инициативасы яки Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән бер өлеше депутатлар төркеме инициативасы буенча чакырыла.

2. Район Советы утырышы анда район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашканда хокуклы (кворум). Кворум Район Советы утырышы башланганда һәм төшке ашка тәнәфестән соң билгеләнә.

3. Әгәр Район Советы утырышына Район Советына сайланган депутатлар санынннан өчтән икедән кимрәк өлеше килсә, Район Башлыгы карары белән утырыш җиде көннән дә артык булмаган башка вакытка күчерелә.

4. Совет утырышларында чакырылган затлар – хокук чыгару инициативасы субъектлары яисә аларның вәкилләре, Совет утырышын оештыруны тәэмин итүче Совет аппараты хезмәткәрләре, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре, гражданнар катнаша ала. Совет утырышына чакырылган затларның саны турындагы мәсьәлә Совет президиумы тарафыннан хәл ителә, шул исәптән Совет комитетлары, депутат берләшмәләре, депутатлар тәкъдиме буенча да. Совет утырышында катнашырга теләгән гражданнар Совет Рәисе исеменә язма гариза җибәрәләр.

5. Район Советы депутатлары һәм чакырылган затлар чираттагы утырышны уздыру вакыты һәм урыны, Район Советы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында өч көннән дә соңга калмыйча, ә чираттан тыш утырыш уздыру көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә. Район Советы утырышын үткәрү урыны һәм вакыты турында хәбәр массакүләм мәгълүмат чараларында бастырылырга мөмкин.

**28 статья**

1. Район Советы утырышы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы гимннары белән ачыла һәм ябыла.

2. Район Советы утырышлары җиһазландырылган залларда үткәрелә, анда муниципаль район флагы һәм гербы урнаштырыла.

3. Район Советының утырышлар залында Район Башкарма комитеты, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре өчен махсус урыннар билгеләнә.

4. Район Советы массакүләм мәгълүмат чаралары тәкъдим итүе буенча Район Советында әлеге массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияли ала.

5. Район Советы аккредитацияләнгән журналистларны Район Советы эше турында мәгълүмат һәм материаллар белән тәэмин итә.

**29 статья**

1. Район Советы утырышына килгән депутатларны теркәү Район Советы утырышы ачылганчы бер сәгать алдан башлана.

2. Депутатларны теркәүне Район Советы аппараты, ә утырыш ачылганнан соң, Район Советы секретариаты оештыра.

**30 статья**

1. Район Советы утырышын Район Башлыгы, ул булмаган очракта – Район Башлыгы урынбасары алып бара. Әгәр Район Башлыгы яки аның урынбасары Район Советы утырышында булмаса, Район Советы утырышта вакытлыча рәислек итүче депутатны үз составыннан сайлый.

2. Район Советы утырышында рәислек итүче:

1) утырышларны ача һәм яба;

2) депутатларга утырышка чакырылучылар составы турында хәбәр итә;

3) Район Советы утырышларын алып бара, әлеге Регламентның һәм утырышның расланган эш тәртибе үтәлешен тәэмин итә;

4) утырышта кворум булуны контрольдә тота;

5) докладлар һәм чыгышлар өчен сүз бирә;

6) Район Советы карарлары проектларын, карала торган мәсьәләләр буенча депутатлар тәкъдимнәрен тавышка куя, аларны тавыш бирүгә кую эзлеклелеген һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен игълан итә;

7)секретариаттан кергән гаризаларны, белешмәләрне, депутатларның тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен игълан итә;

8) утырыш залында тәртип булуны тәэмин итә;

9) карала торган мәсьәләләр буенча якларның хезмәттәшлегенә, позицияләрен якынайтуга ярдәм итә;

10) фикер алышулар барышында фикер алышына торган мәсьәлә буенча төрле фикерләрне ачыклауны тәэмин итә, кирәк булганда тиешле аңлатмалар биреп, фикер каршылыкларын бетерү һәм утырыш барышында барлыкка

килгән башка мәсьәләләрне хәл итү максатларында консультацияләр үткәрүне оештыра;

11) кирәк булганда депутатлар, комитетлар белән консультацияләр үткәрә, каршылыкларны бетерү максатыннан, вакытлы комиссияләр эшен оештыра;

12) Район Советы утырышында Район Советы секретариаты һәм аппараты эшен оештыра.

3. Рәислек итүче карала торган мәсьәләләрнең асылы буенча башка депутатлар өчен әлеге Регламентта билгеләнгән вакыттан артык чыгыш ясарга, әгәр алар әлеге Регламент таләпләренә каршы килмәсә, депутатлар чыгышларын өзәргә һәм комментарийлар бирергә хокуклы түгел.

**31 статья**

1. Утырыш үткәрү вакытында ачык тавыш бирү юлы белән Район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән Район Советы депутатлары арасыннан Район Советы утырышы секретариаты сайлана.

2. Күрсәтелгән органның шәхси составы Район Башлыгы тарафыннан кертелә.

3. Район советы утырышы секретариаты:

1) утырыш беркетмәсен алып баруны оештыра;

2) секретариатка керү вакыты күрсәтелгән чыгыш ясаучыларны язуны алып бара, утырышта рәислек итүчегә чыгыш ясау өчен язылган мәгълүматлар турында белешмәләр бирә;

3) депутат таләпләрен, сорауларны, белешмәләрне, хәбәрләрне, гаризаларны, тәкъдимнәрне һәм башка материалларны терки, аларны утырышта рәислек итүчегә, редакция комиссиясенә, Район Советының башка органнарына җибәрә;

4) утырышта депутатларга кирәкле материалларны тиражлауны һәм таратуны оештыра;

5) утырышка килгән депутатларны теркәү нәтиҗәләрен анализлый һәм Район Советына депутатларның утырышларда булмау сәбәпләре турында хәбәр итә;

6) тавыш бирү нәтиҗәләрен терки;

7) утырыш барышында барлыкка килгән мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирә һәм депутатларга хәбәр итә;

8) Район Советы утырышы беркетмәсен рәсмиләштерә һәм аны, кул кую өчен, Район Башлыгына тапшыра.

9) Район Советы утырышында Район Советы депутатлары эшчәнлеген тәэмин итү буенча башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

4. Депутатлар мөрәҗәгатьләрен һәм фикерләрен тулырак исәпкә алу, Район Советы тарафыннан карала торган мәсьәлә буенча карар проектының ахыргы текстын эшләү өчен, рәислек итүче яисә башка депутатлар тәкъдиме белән утырышта редакция комиссиясе сайлана.

**32 статья**

1. Район Советының чираттагы утырышының көн тәртибе һәм эш тәртибе Район Башлыгы тарафыннан әзерләнә һәм Район Советының эш планнарын һәм карарларын, шулай ук кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, Район Советы каравына тапшырыла. Чираттагы утырышның көн тәртибенә сораулар кертү инициативасы хокукына Район Башлыгы, Район Советы депутатлары, аның президиумы, даими комиссияләр, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе һәм хокук чыгару инициативасының башка субъектлары ия.

2. Район Советының чираттан тыш утырышларының көн тәртибе аларны үткәрү инициаторлары тарафыннан тәкъдим ителә. Чираттан тыш утырыш уздыру инициаторлары язма рәвештә үзләре тәкъдим иткән мәсьәләне тиз арада карау кирәклегенә нигезләр, шулай ук әлеге Регламент нигезендә Район Советы утырышында карау өчен документлар тапшырырга тиеш.

3. Көн тәртибе һәм эш тәртибе Район Советы утырышында утырышта рәислек итүче тәкъдиме буенча Район Советы тарафыннан тикшерелә һәм раслана.

4. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр көн тәртибенә һәм эш тәртибенә Район Советы депутатлары тарафыннан утырыш секретариатына язма рәвештә тапшырыла яки чыгышларында бәян ителә. Язма рәвештә кергән тәкъдимнәр керү тәртибендә утырышта рәислек итүче тарафыннан игълан ителә.

5. Көн тәртибендәге мәсьәләләрне карау тәртибе, чираттагы мәсьәләне карауга күчү яисә алдагы, әмма хәл ителмәгән мәсьәләләрнең берсенә кире кайту утырышта катнашучы депутатлар саныннан күпчелек тавыш белән яисә, депутат каршылыклары булмаганда, рәислек итүче тавыш бирмичә генә гамәлгә ашырыла.

6. Район Советы Район Советы утырышында расланган көн тәртибендәге барлык мәсьәләләрне дә карарга, яисә каралмаган мәсьәләләрне киләсе утырышка күчерү турында карар кабул итәргә тиеш. Күчерелгән мәсьәләләр, Район Советы тарафыннан башка карар кабул ителмәсә, киләсе утырышның көн тәртибендә өстенлеккә ия.

**33 статья**

Район Советы утырышына материаллар, кагыйдә буларак, утырышка кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча депутатларга, Район Башкарма комитеты Җитәкчесенә, хокук чыгару инициативасының башка субъектларына җибәрелә.

**34 статья**

1. Район Советы утырышлары, кагыйдә буларак, 10 нан 13 сәгатькә кадәр үткәрелә. Район Советы утырышы башлануның башка вакыты Район Башлыгы тарафыннан Район Советы утырышын чакыру турында карар кабул иткәндә билгеләнергә мөмкин. Утырыш үткәрү вакытын озайту утырышта рәислек итүче тәкъдиме буенча Район Советы тарафыннан кабул ителә.

2. Утырышның көн тәртибе (вакыты һәм саны) утырыш башланганда рәислек итүче тәкъдиме буенча Район Советы тарафыннан раслана.

3. Докладлар өчен вакыт рәислек итүче тарафыннан докладчылар белән килешү буенча билгеләнә, ләкин 45 минуттан да артык түгел, өстәмә докладлар өчен – 10 минут, докладлар һәм карарлар проектлары буенча фикер алышуларда чыгыш ясау өчен – 5 минутка кадәр, фикер алышуларда кабат чыгыш ясау өчен – 3 минутка кадәр, утырышларны алып бару тәртибе, тавыш бирү мотивлары буенча чыгышлар ясау, сораулар, тәкъдимнәр, хәбәрләр һәм белешмәләр кертү өчен – 1 минутка кадәр.

4. Билгеләнгән вакыт узгач, рәислек итүче бу хакта чыгыш ясаучыны кисәтә, аннары аның чыгышын өзәргә хокуклы.

5. Утырышта катнашучы депутатларның күпчелеге ризалыгы белән яисә депутатлар каршылыклары булмаган очракта тавыш бирмичә генә рәислек итүче доклад, өстәмә доклад яисә чыгыш ясау өчен вакытны озайтырга яисә кыскартырга хокуклы.

6. Һәр утырышның ахырында, гаризалар кергән очракта, көн тәртибендәге «Төрлесеннән» мәсьәләсе кысаларында белешмәләр, игъланнар, мөрәҗәгатьләр, гаризалар өчен 30 минут вакыт бирелә. Әлеге хәбәрләр буенча фикер алышулар булмый.

**35 статья**

1. Докладтан һәм өстәмә докладтан соң Район Советы утырышының көн тәртибе буенча депутатларга докладчыга, өстәмә докладчыга сораулар бирү мөмкинлеге бирелә. Сораулар язма рәвештә яки телдән бирелә. Район Советы депутаты өчтән артык сорау бирә алмый.

2. Кирәк булганда, Район Советы, килгән депутатлар саныннан күпчелек тавыш белән сораулар бирүне туктату һәм доклад буенча фикер алышуларга күчү яки Район Советы карары проектына күчү турында карар кабул итә.

3. Депутат фикер алышуларда ике тапкырдан да артык чыгыш ясый алмый. Өстәмә чыгыш ясау хокукы Район Советы карары белән генә бирелергә мөмкин. Чыгыш ясау хокукын башка затка тапшыру рөхсәт ителми.

4. Фикер алышуларны туктату утырышта катнашучы депутатлар саныннан күпчелегенең ачык тавыш бирү юлы белән Район Советы карары белән башкарыла Фикер алышуларны туктату турындагы мәсьәләне куйганда, рәислек итүче депутатларга чыгыш ясау өчен язылучылар саны турында хәбәр итә һәм язылучыларның кайсылары чыгыш ясауны таләп итүен ачыклый. Әгәр депутат, фикер алышулар туктатылуга бәйле рәвештә чыгыш ясау мөмкинлеге алмаган булса, Район Советы утырышы беркетмәсенә кушымта итеп теркәү өчен, секретариатка үз чыгышының текстын бирә ала.

5. Фикер алышулар туктатылганнан соң докладчы һәм өстәмә докладчы 5 минутлык йомгаклау чыгышына хокуклы.

**36 статья**

1. Район Советы депутаты, катнашучы башка зат утырышта рәислек итүче аңа сүз биргәннән соң чыгыш ясый.

2. Чыгыш ясау өчен сүз гаризалар керү тәртибендә бирелә. Рәислек итүчегә утырышны алып бару тәртибе буенча искәрмәләр белдерү өчен, шулай ук тавышка куелган формулировкаларны ачыклау өчен, сүз чиратсыз бирелә. Рәислек итүче тарафыннан шулай ук тавыш бирү мотивлары буенча чыгышлар, белешмә, аңлатмалар бирү өчен һәм башка процедура мәсьәләләре буенча искәрмә ясалырга мөмкин..

3. Язылмыйча чираттан тыш чыгыш ясау хокукына Район Башлыгы, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе, утырышта рәислек итүче ия.

**37 статья**

1. Район Советы утырышында район Советы депутаты үзе сүз алган көн тәртибендәге мәсьәлә буенча чыгыш ясарга тиеш. Район Советы депутатлары чыгышларына комментарийлар бирергә, чыгыш ясаучыларга тасвирлама бирергә беркем дә хокуклы түгел.

2. Район Советы утырышында чыгыш ясаучы тупас һәм ямьсез сүзләр һәм гамәлләр кылырга, законсыз һәм көч куллану гамәлләренә өндәргә тиеш түгел. Әлеге таләпләрне бозган очракта рәислек итүче мондый сүзләргә, чакыруларга һәм гамәлләргә юл куймау турында рәсми кисәтү ясый.

3. Тәртипне кабат бозганда, рәислек итүче депутат чыгышын туктата. Әлеге депутат, катнашучы депутатлар саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Район Советы карары белән утырыш дәвамында сүз алудан мәхрүм ителергә мөмкин.

4. Әгәр чыгыш ясаучы фикер алышына торган темадан читкә китсә, рәислек итүче аны тикшерелә торган мәсьәлә темасына кайтуга өндәргә хокуклы.

**38 статья**

Район Советы депутаты булмаган утырышта катнашучы зат тарафыннан тупас тәртип бозу очрагы күзәтелгәндә, рәислек итүче күрсәтмәсе буенча ул утырыш залыннан чыгарылырга мөмкин.

**39 статья**

1. Район Советының һәр утырышында беркетмә, кирәк булган очракта аудио-видео язма алып барыла.

2. Утырыш беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) Район Советы утырышын үткәрү датасы, урыны һәм тәртип номеры;

2) Район Советы утырышында катнашучы депутатларның фамилиясе, исеме, атасының исеме күрсәтелгән билгеләнгән саны;

3) рәислек итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы;

4) Район Советы утырышының көн тәртибе мәсьәләләре, Район Советы каравына чыгарылган һәр мәсьәлә буенча чыгыш ясаган докладчыларның, өстәмә докладчыларның фамилияләре, инициаллары, вазыйфалары;

5) тавыш бирү өчен барлык тәкъдимнәрне формулировкалары һәм барлык тавыш бирү нәтиҗәләре, «яклы», «каршы» тавыш биргән депутатлар санын яисә тыелып калган депутатлар санын күрсәтеп, ә исемле тавыш бирү уздырганда – шулай ук депутатларның фамилияләрен һәм инициалларын күрсәтеп.

3. Беркетмәгә Район Советы кабул иткән актларның тулы текстлары, карарлар проектлары һәм башка материаллар, чыгышлар текстлары яки утырыш барышында секретариатка депутатлар һәм чыгыш ясаучылар тарафыннан тапшырылган башка материаллар кушымта итеп бирелә.

4. Район Советы утырышы беркетмәсе Район Советы утырышы тәмамланганнан соң ун көн дәвамында рәсмиләштерелә, секретариат әгъзалары тарафыннан визалана һәм Район Башлыгы тарафыннан имзалана.

5. Беркетмә ике нөсхәдә рәсмиләштерелә. Беренчесе билгеләнгән тәртиптә архивка тапшырыла. Беркетмәнең икенче нөсхәсе Район Советы аппаратында була һәм Район Советы депутатларына, Район халкына аларның үтенече буенча танышу өчен бирелә.

## 5.1 бүлек. Депутат берләшмәләре

### 39.1 статья

1. Уртак эшчәнлек һәм Совет тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча бердәм позиция белдерү, сайлаучылар наказларын үтәү өчен депутатлар партия, территориаль, һөнәри һәм башка принцип буенча даими яисә вакытлы депутат берләшмәләренә – фракцияләргә һәм төркемнәргә берләшергә хокуклы.

2. Депутат берләшмәсе составында *кимендә ун депутат булырга тиеш.*

3. Фракцияне, депутатлар төркемен теркәү өчен Район Башлыгы исеменә түбәндәге документлар тапшырыла:

а) фракция, депутат төркеме төзү турында хәбәрнамә;

б) фракцияне, депутат төркемен төзү турындагы карарны үз эченә алган, аның рәсми исеме, исемлек составы турында, шулай ук Совет утырышларында, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм иҗтимагый берләшмәләрдә аның мәнфәгатьләрен якларга вәкаләтле затлар турында мәгълүматны күрсәтеп, фракциянең оештыру җыелышы беркетмәсе;

в) депутатларның фракциягә, депутат төркеменә керүләре турындагы язма гаризалары.

4. Тәкъдим ителгән документлар әлеге Регламент таләпләренә туры килмәсә, фракция, депутат төркемен теркәүдән баш тартырга мөмкин.

5. Теркәлгән барлык депутат берләшмәләре Советның депутат берләшмәләре реестрына кертелергә тиеш.

6. Район Башлыгы Советның якындагы утырышында депутатларга депутат берләшмәсе булдыру турында игълан итә. Яңа төзелгән фракциянең, депутатлар төркеменең максатлары һәм бурычлары турында чыгыш ясау өчен аның Җитәкчесенә шул ук утырышта вакыт бирелергә мөмкин.

7. Әлеге Регламент нигезендә теркәлмәгән депутат берләшмәләре, фракцияләр депутат төркеме хокукларыннан файдалана алмый.

8. Нинди дә булса фракция, депутатлар төркеме составына кермәгән депутатлар бәйсез депутатлар булып санала.

9. Депутат бары тик бер депутат берләшмәсендә генә торырга хокуклы. Аларны төзегәндә депутат төркемнәренең берсенә дә кермәгән, яисә депутат төркеменнән чыккан депутатлар алга таба фракцияләрнең, депутат төркемнәренең теләсә кайсысына фракция, депутатлар төркеме ризалыгы белән керә ала.

10. Фракцияләр һәм депутат төркемнәре үз составларындагы үзгәрешләр турында Советка мәгълүмат бирергә тиеш. Әлеге мәгълүмат Район Башлыгы яки Район Башлыгы урынбасары тарафыннан Советның якындагы утырышында депутатлар игътибарына җиткерелә.

**39.2 статья**

1. Депутат берләшмәләренең эшчәнлеге алар тарафыннан мөстәкыйль оештырыла.

2. Фракцияләр, депутатлар төркемнәре депутат төркемнәре фракцияләр җыелышларында карарлар кабул итә. Фракция, депутатлар төркеме карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә.

3. Фракция, депутат төркеме җитәкчелеген аны фракция әгъзаларының, депутат төркеменең гомуми саныннан күпчелек тавыш белән сайланучы Җитәкче башкара.

**39.3 статья**

1. Депутат берләшмәләренең хокуклары:

а) Район Башлыгы һәм Район Башлыгы урынбасары сайлау өчен кандидатуралар турында алдан фикер алышырга;

б) Советта карала торган мәсьәләләр буенча фикер алышу үткәрергә;

в) башка фракцияләр, депутат төркемнәре белән консультацияләр һәм башка килештерү чаралары үткәрергә;

г) Совет депутатлары арасында үз программаларын, тәкъдимнәрен, мөрәҗәгатьләрен һәм башка материалларны таратырга;

д) фикер алышына торган теләсә нинди мәсьәлә буенча Совет утырышында чыгыш ясарга;

е) үз вәкилләрен вакытлы депутат комиссияләренә, эш төркемнәренә, шул исәптән килештерү төркемнәренә кертергә;

ж) Советтагы теләсә кайсы урынга сайлау өчен үз фракциясе, депутат төркеме арасыннан кандидатуралар тәкъдим итәргә;

з) законнар белән тыелмаган башка эшчәнлекне гамәлгә ашырырга.

2. Төрле фракцияләр һәм депутатлар төркемнәре вәкилләре тарафыннан уртак карарлар кабул итү өчен уртак консультацияләр, киңәшмәләр, утырышлар үткәрелергә мөмкин.

**39.4 статья**

1. Ел саен депутат берләшмәләрен яңадан теркәү гамәлгә ашырыла. Фракцияләр, депутат төркемнәре җитәкчеләре Район Башлыгы исеменә фракциянең, депутатлар төркеменең саны һәм составы турында мәгълүматлар җибәрәләр.

2. Фракция, депутат төркеме составында *депутатлар 10 нан кимесә,* бу фактны теркәгәннән соң бер ай узгач, әлеге фракция, депутат төркеме эшчәнлеге туктатылган дип санала һәм Советның законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясе карары белән Советның депутат берләшмәләре реестрыннан төшереп калдырыла.

3. Фракция, депутатлар төркеме үз-үзен таркату турында карар кабул итәргә мөмкин. Үз-үзен таркату турындагы карар фракция, депутатлар төркеме җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм Район Башлыгына җибәрелә. Советның законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясе әлеге фракцияне, Советның депутат берләшмәләре реестрыннан депутатлар төркемен төшереп калдыру турында карар кабул итә.

4. Район Башлыгы Советның якындагы утырышында депутатларга фракция, депутатлар төркеменең эшчәнлеге туктатылуы турында хәбәр итә.

## 6 бүлек. Тавыш бирү һәм карарлар кабул итү тәртибе

**40 статья**

1. Район Советы карарлары, кагыйдә буларак, ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

2. Законнар, муниципаль берәмлек Уставы һәм әлеге Регламентта каралган очракларда, шулай ук Район Советы карары буенча яшерен тавыш бирү үткәрелә.

3. Район Советы карары буенча исемле тавыш бирү үткәрелергә мөмкин. Исемле тавыш бирү кадрлар мәсьәләсе буенча үткәрелә алмый.

4. Депутат тавыш бирү хокукын шәхсән үзе гамәлгә ашырырга тиеш. Тавыш бирү вакытында булмаган депутат тавыш бирү өчен бирелгән вакытка кадәр һәм аннан соң, шул исәптән язма рәвештә дә, үз тавышын бирергә хокуклы түгел.

**41 статья**

1. Ачык тавыш бирү уздырганда тавышларны санауны секретариат алып бара.

2. Тавыш бирү башланыр алдыннан рәислек итүче тавышка куела торган тәкъдимнәрнең саны турында хәбәр итә, аларның формулировкаларын һәм тавышка куела торган эзлеклелеген төгәлләштерә, карар кабул ителергә мөмкин булган тавышларның саны турында искә төшерә.

3. Бер яки ике тәкъдим буенча тавыш биргәндә һәр депутат үз тавышын бер тапкыр бирергә хокуклы: тәкъдим “яклы" яки "каршы", шулай ук тавыш бирүдән тыелып тора ала. Әлеге Регламент буенча депутатларның тиешле саны тавыш биргәндә, тәкъдим кабул ителгән санала.

4. Әгәр бер мәсьәлә буенча икедән артык тәкъдим тавышка кертелсә, һәр депутат һәр тәкъдимгә "яклы" яисә "каршы" тавыш бирергә, шулай ук теләсә кайсы тәкъдим буенча тавыш бирүдән (рейтинглы тавыш бирү) тыелып торырга хокуклы. Иң күп тавыш җыйган ике тәкъдим, әлеге статьяның өченче өлешендә каралган тәртиптә, кабат тавышка куела. Бер тәкъдим дә әлеге Регламент буенча карар кабул итү өчен кирәкле тавышлар санын җыймаса, рәислек итүче тәкъдиме белән, яңа карар проектын эшләү өчен, депутат килештерү комиссиясе төзелә.

5. Тавыш бирү тәмамланганнан соң, утырышта рәислек итүче аның нәтиҗәләрен игълан итә. Тавыш бирү нәтиҗәләре Район Советы утырышы беркетмәсенә кертелә.

**42 статья**

1. Яшерен тавыш бирү уздыру һәм аның нәтиҗәләрен билгеләү өчен Район Советы депутатлар арасыннан хисап комиссиясен сайлый. Хисап комиссиясенә кандидатуралары сайланучы органнар составына яки сайланучы вазыйфаларга тәкъдим ителүче депутатлар керә алмый.

2. Хисап комиссиясе үз составыннан комиссия рәисен һәм секретарен сайлый һәм бу хакта беркетмә төзелә.

3. Комиссия карарлары аның әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм комиссия рәисе һәм секретаре кул куя торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

4. Тавыш бирү өчен бюллетеньнәр хисап комиссиясе контрольлегендә үзе билгеләгән формада һәм билгеле бер күләмдә әзерләнә. Бюллетеньнәрдә тавыш бирү өчен кирәкле мәгълүмат булырга тиеш. Карарлар проектлары буенча тавыш бирү өчен бюллетеньнәрдә яисә сайлау вазыйфасына бердәнбер кандидатура булганда "яклы" һәм "каршы" сүзләре торырга тиеш.

5. Тавыш бирү вакыты һәм урыны, аны уздыру тәртибе хисап комиссиясе тарафыннан әлеге Регламент нигезендә билгеләнә һәм комиссия рәисе тарафыннан игълан ителә.

6. Тавыш бирүне уздыру өчен комиссия утырышта катнашкан һәр депутатка тавыш бирү өчен бер бюллетень бирә.

7. Бюллетеньне тутыру бюллетеньдә депутат тавыш бирә торган кандидатның фамилиясен, ә карар проекты буенча бюллетеньдә (карар варианты) яисә бер кандидатуралы булганда тәкъдим ителә торган карарлар яисә кандидатның фамилиясе вариантлары янында "яклы" яисә "каршы"

сүзләрен кую юлы белән башкарыла. "Яклы" сүзен дә, "каршы" сүзен дә,кандидатларның барысының фамилиясен сызу шулай ук тутырылмаган бюллетень тавыш бирүдән тыелу булып санала.

8. Тавыш бирү өчен бюллетень тавыш бирү кабинасында тутырыла һәм тавыш бирү өчен куелган урнага төшерелә.

9. Тавыш бирү тәмамланганнан соң, хисап комиссиясе урнаны ача, гамәлдәге һәм гамәлдә булмаган бюллетеньнәр санын билгели һәм тәкъдимгә каршы яисә яклап бирелгән тавышларны санауны башкара. Тавышларны санаганда Район Советы депутатлары катнаша ала.

10. Тиешле формада булмаган бюллетеньнәр, ә вазыйфаи затны сайлаганда бер вазыйфага ике яки аннан күбрәк кандидатның фамилияләре калган бюллетеньнәр гамәлдә түгел дип санала.

11. Яшерен тавыш бирү нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмә төзи, ул барлык хисап комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Район Советы утырышында укыла. Хисап комиссиясе докладны буенча Район Советы ачык тавыш бирү юлы белән яшерен тавыш бирү нәтиҗәләрен раслау турында карар кабул итә.

**43 статья**

1. Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә биштән бере таләбе буенча исемле тавыш бирү үткәрелә.

2. Исемле тавыш бирү үткәрү һәм аның нәтиҗәләрен билгеләү өчен Район Советы депутатлар арасыннан хисап комиссиясен сайлый.

3. Район Советы утырышында яшерен һәм исемле тавыш бирү үткәрелгәндә, Район Советы аларны оештыруны бер хисап комиссиясе составына йөкли ала.

4. Исемле тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертү өчен секретариатка бирелә һәм Район Советы утырышында игълан ителә, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыга.

**44 статья**

Шул ук мәсьәлә буенча кабат тавыш бирү Район Советының әлеге мәсьәлә буенча карар кабул итү өчен кирәкле шундый ук күпчелек тавыш белән кабул ителгән карары буенча рөхсәт ителә. Моның өчен тавышларны санаганда хаталар, мәсьәләне тавышка куйганда аңлашылмаучанлык, әлеге Регламентның башкача бозылуы нигез булырга мөмкин.

**45 статья**

1. Процедура мәсьәләләре буенча карарлар, әлеге Регламентта башкача билгеләнмәгән булса, утырышта катнашкан Район Советы депутатлары санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм утырыш беркетмәсендә чагылдырыла.

2. Процедура мәсьәләләренә түбәндәгеләр керә:

1) утырышның көн тәртибе проектына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

2) утырышның көн тәртибен раслау турында;

3) утырышның көн тәртибенә яңа мәсьәлә өстәү турында ;

4) Район Советы утырышы секретариатын һәм башка органнарын сайлау турында;

5) утырышны берничә этапта үткәрү турында;

6) утырыштагы тәнәфес, утырышны күчерү яки ябу турында;

7) чыгыш ясау өчен өстәмә вакыт бирү турында;

8) утырышның көн тәртибенә куелган мәсьәлә буенча фикер алышуларны күчерү яисә туктату турында;

9) утырышның көн тәртибе мәсьәләләренә күчү (кире кайту) туында;

10) Тиешле комитет яки Район Советы комиссиясе каравына сорау кертү турында;

11) фикер алышмыйча гына тавыш бирү турында;

12) хокукый актлар проектларына төзәтмәләрне кабул итү яисә кире кагу турында;

13) ябык утырыш үткәрү турында;

14) утырышта рәислек итүче функцияләрен тапшыру турында;

15) Район Советы тарафыннан каралган карарлар проектлары һәм башка мәсьәләләр буенча кирәкле белешмәләр һәм бәяләмәләр бирү өчен затларны утырышка чакыру турында;

16) утырышта катнашучыларга бирелә торган мәгълүматны, белешмәләрне игътибарга алу турында;

17) тавыш бирүне уздыру ысулын үзгәртү турында;

18) өстәмә теркәү үткәрү турында;

19) тавышларны яңадан исәпләү турында;

20) Район Советы утырышын үткәрү вакытын озайту турында;

21) депутат (депутатлар) мөрәҗәгатендә булган сорауларга җаваплар өчен вазыйфаи затны утырышка чакыру турында;

22) Район Башкарма комитетының үз эшчәнлеге турында чираттан тыш хисап бирүе хакында;

23) карарлары әлеге Регламент нигезендә Район Советы утырышында катнашкан депутатларның санынннан чагыштырмача күпчелек тавыш белән кабул ителгән башка мәсьәләләр.

## 7 бүлек. Район Советының хокукый актлары

### 46 статья

1. Район Советы, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Район Уставы белән билгеләнгән компетенциясе кысаларында, норматив һәм башка хокукый актлар, шулай ук гаризалар, мөрәҗәгатьләр, декларацияләр кабул итә.

2. Норматив-хокукый актлар, шулай ук норматив-хокукый булмаган актлар Район Советы карарлары рәвешендә кабул ителә.

3. Район Советының хокукый актлары көн тәртибенә кертелгән мәсьәлә кысаларында кабул ителә.

4. Район Советының хокукый актлары, шулай ук Район Советы тарафыннан кабул ителгән гаризалар, мөрәҗәгатьләр, декларацияләр кабул ителгән көннән өч көн эчендә Район Башлыгы тарафыннан имзалана һәм Район Уставында билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерелә.

**47 статья**

Процедура мәсьәләләре буенча Район Советы тарафыннан кабул ителгән карарлар аерым акт белән рәсмиләштерелми. Әлеге карарлар Район Советы утырышы беркетмәсендә чагылдырыла һәм, кирәк булганда, Район Башлыгы кул куйган беркетмәдән өземтәләр белән рәсмиләштерелә.

## 8 бүлек. Район Советы тарафыннан норматив хокукый актларны кабул итү тәртибе

**48 статья**

1. Норматив хокукый актлар проектлары Район Советына Район Советы депутатлары, Район Башлыгы, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, гражданнарның инициатив төркемнәре, шулай ук Район Уставында билгеләнгән хокук чыгару инициативасының башка субъектлары тарафыннан кертелә ала.

2. Норматив хокукый акт проектын керткәндә, Район Советына түбәндәгеләр тәкъдим ителергә тиеш:

1)норматив хокукый акт проектының тексты;

2) әлеге норматив хокукый актны кабул итүнең максатка ярашлыгын нигезләгән аңлатма язуы;

3) финанс-икътисадый нигезләү (гамәлгә ашыру җирле бюджеттан матди чыгымнар таләп итә торган норматив хокукый акт проекты кертелгән очракта);

4) Район Советының гамәлдән чыгару, үзгәрешләр, өстәмәләр кертү яки әлеге проектны кабул итүне таләп итә торган хокукый актлары исемлеге.

3. Җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгаруны, җирле бюджет акчаларыннан чыгымнарны гамәлгә ашыруны күздә тоткан Район Советы карарлары проектлары Район Советы каравына Район Башкарма комитеты Җитәкчесе яки Район Башлыгы инициативасы белән кертелергә мөмкин. Күрсәтелгән бәяләмә Район Советына, карар проектын Район Башкарма комитетына тапшырганнан соң, утыз көн эчендә тапшырыла.

4. Норматив хокукый акт проекты һәм аңа кушып бирелә торган материаллар Район Башлыгы исеменә язма рәвештә җибәрелә.

**49 статья**

1. Кергән норматив хокукый акт проекты һәм аңа кушып бирелә торган материаллар Район Советы аппараты тарафыннан проект Район Советына кергән көнне теркәлә.

2. Район Башлыгы, теркәгән көннән соң бер тәүлек эчендә, Район Советы аппараты белән берлектә алдан карау һәм проект буенча бәяләмә әзерләү өчен, карамагында тәкъдим ителә торган мәсьәлә булган Район Советы комитетына (алга таба – баш комитет) кушып бирелгән материаллары белән бергә норматив хокукый акт проектын җибәрә.

3. Район башлыгы, тиешле даими комиссия тәкъдимнәрен исәпкә алып, проектны карауга әзерләү вакытын билгели, ул, кагыйдә буларак, бер айдан артып китә алмый.

4. Әгәр тәкъдим ителгән норматив хокукый акт проекты әлеге Регламент таләпләренә җавап бирми яисә аның буенча әлеге Регламентның 48 статьясында күрсәтелгән кирәкле материаллар тапшырылмаган булса, әлеге проект Район Башлыгы тарафыннан, проектка карата билгеләнгән таләпләрне үтәү өчен, кире кайтарылырга мөмкин.

5. Район Советы тарафыннан беренче укылышта аны караганчы, норматив хокукый акт проекты буенча Район Советы тарафыннан расланган ачык тыңлаулар турында Нигезләмә һәм Район Уставында билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган ачык тыңлаулар билгеләнергә мөмкин.

**50 статья**

1. Тиешле даими комиссиядә норматив хокукый акт проектын карау, проект буенча бәяләмә әзерләү тәртибе комиссия тарафыннан әлеге Регламент нигезендә мөстәкыйль билгеләнә.

2. Проектлар өстендә эшләү өчен, даими комиссия проект инициаторы яисә аның вәкилләре катнашырга хокуклы эшче төркемнәр төзи ала.

3. Норматив хокукый актларның альтернатив проектлары төп проект белән даими комиссия тарафыннан бер үк вакытта карала.

4. Кирәк булганда, норматив хокукый акт проекты даими комиссия тарафыннан экспертизага җибәрелергә мөмкин, алар буенча Район Башкарма комитеты бәяләмәсе, дәүләт органнары фикере соратылырга мөмкин.

5. Норматив хокукый акт проектын беренче укылышта кабул иткәнгә кадәр проектны керткән хокук чыгару инициативасы субъекты түбәндәгеләргә хокуклы:

1) тиешле комиссия тәкъдиме буенча проектның текстын үзгәртергә;

2) тиешле комиссия тәкъдиме буенча яисә үз инициативасы белән кертелгән проектны язма гариза нигезендә кире алырга.

6. Норматив хокукый акт проектын даими комиссиядә тикшерү, проект керткән хокук чыгару инициативасы субъекты вәкилен чакырып, ачыктан-ачык үткәрелә.

7. Комссия эшендә катнашмаган даими комиссия әгъзасы комиссиягә каралырга тиешле үз искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен җибәрергә хокуклы.

Комисиянең карау нәтиҗәләре турында искәрмәләр һәм тәкъдимнәрне телдән әлеге искәрмәләр һәм тәкъдимнәрне юллаган Район Советы депутатларына җиткерәләр.

8. Тиешле комиссия әгъзалары булмаган Район Советы депутатлары, хокук чыгару инициативасы субъектлары вәкилләре, Район Башкарма комитеты, дәүләт органнары, бәяләмәләр, тасвирламалар, тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирү өчен норматив хокукый акт проекты җибәрелгән башка оешмалар вәкилләре даими комиссия утырышларында әлеге проект буенча фикер алышканда тавыш бирү хокукы белән катнашырга хокуклы.

9. Тиешле даими комиссия Район Башлыгына норматив хокукый акт проектын алдан карау нәтиҗәләре буенча комиссиянең әлеге проект буенча Район Советы тарафыннан проектны кабул итү яисә кире кагу турында дәлилләнгән тәкъдимен үз эченә алган бәяләмәсен тәкъдим итә. Тиешле даими комиссия бәяләмә белән бергә әлеге проект буенча Район Советы карары проектын тәкъдим итә.

10. Район Башлыгына кергән норматив хокукый акт проекты Район прокурорына алдан, Район Советы утырышы үткәрелгәнче җибәрелә.

11. Район Советы тарафыннан карауга әзерләнгән норматив хокукый акт проекты Район Башлыгы тарафыннан Район Советының алдагы утырышының көн тәртибенә кертелә.

**51 статья**

1. Гражданнарның хокук чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән норматив хокукый акт проекты Район Советы тарафыннан аның ачык утырышында кертелгәннән соң өч ай эчендә каралырга тиеш.

2. Норматив хокукый акт проектын керткән гражданнарның инициатив төркеме вәкилләре, әлеге Регламент нигезендә үзләре керткән проектны карау вакыты һәм урыны турында алдан хәбәр ителә, алар комитет, Район Советы утырышларында әлеге проект буенча фикер алышканда катнашырга һәм аның буенча үз позициясен белдерергә хокуклы.

3. Әгәр гражданнарның хокук чыгару инициативасын гамәлгә ашыру тәртибендә кертелгән норматив хокукый акт проектын караганда, Район Советы тарафыннан гражданнарның тиешле инициативалы төркеме вәкиле юк икән, проектны карау Район Советының икенче утырышына күчерелә. Әгәр Район Советы утырышында проектны кабат караганда әлеге вәкилләр янә юк икән, әлеге норматив хокукый акт проекты Район Советы тарафыннан күрсәтелгән вәкилләр катнашуыннан тыш каралырга мөмкин. Мондый очракта проект турында фикер алышу баш комитет вәкиле докладыннан башлана.

**52 статья**

1. Район Советында норматив хокукый актлар проектларын карау, Район Советы тарафыннан конкрет проектка карата башка карар кабул ителмәсә, ике укылышта гамәлгә ашырыла.

2. Район Советының норматив хокукый актлары, кагыйдә буларак, түбәндәге процедура буенча кабул ителә:

1) проектны тикшерү;

2) проектны нигез итеп кабул итү;

3) төзәтмәләр кертү;

4) хокукый актны тулаем кабул итү.

**53 статья**

1. Норматив хокукый акт проектын беренче укылышта карау хокук чыгару инициативасы субъекты яисә аның вәкиленең нотыгыннан һәм, кагыйдә буларак, тиешле даими комиссиянең өстәмә докладыннан башлана.

2. Проектны караганда, Район Советы депутатларының, Район Башкарма комитеты Җитәкчесенең, экспертларның һәм фикер алышуда катнашу өчен чакырылган башка затларның тәкъдимнәре һәм искәрмәләре тыңлана.

3. Фикер алышулардан соң, проект буенча Район Советы түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

- проектны беренче укылышта кабул итәргә,

- проектны кире кагарга.

4. Проект беренче укылышта кабул ителгән дип аның өчен Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелеге тавыш биргәндә санала. Әгәр тавыш бирү йомгаклары буенча проектны беренче укылышта кабул итү турында тәкъдим кирәкле тавышлар санын җыймаса, ул өстәмә тавыш бирмичә генә кире кагылган дип санала, яисә Район Советы әлеге проектны эшләп бетерергә җибәрү турында карар кабул итәргә мөмкин. Проект буенча карар өстәмә тавыш бирмичә генә Район Советының тиешле акты белән рәсмиләштерелә.

5. Район Советының норматив хокукый акт проектын беренче укылышта кабул итү турында карарында проектка төзәтмәләр кертү срогы билгеләнә, тиешле даими комиссия күрсәтелә, аңа төзәтмәләр карау йөкләнә һәм проектны икенче укылышта карауга кертү срогы билгеләнә.

6. Район Советы беренче укылышта кабул ителгән проектны халыкка фикер алышуга һәм (яки) ачык тыңлауларга кую турында карар кабул итәргә мөмкин. Законнар, Район Уставы нигезендә ачык тыңлаулар үткәрү мәҗбүри, ә норматив хокукый акт проекты буенча аны беренче укылышта караганчы Район Советы тарафыннан ачык тыңлаулар үткәрелмәгән очракларда, Район Советы яки Район Башлыгы әлеге проект буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында карар кабул итә.

7. Бер үк мәсьәлә буенча альтернатив проектлар керткәндә, Район Советы аларны беренче укылыш барышында бер үк вакытта карый һәм алга таба эш өчен аларның кайсысын нигез итеп алу турында карар кабул итә, бу шулай ук башка проектларны кире кагуны аңлата. Кире кагылган проектлар тулаем алганда да, өлешләп тә Район Советына беренче укылышта кабул ителгән проект буенча соңгы карар кабул ителгәнчегә кадәр кабат кертелә алмый.

8. Проектны Район Советы карары белән эшләп бетерүгә җибәргән очракта, эшләнеп беткән проектны Район Советында карау өчен тапшыру срогы билгеләнә.

**54 статья**

1. Проектка төзәтмәләр проектның аерым нигезләмәләре редакциясенең үзгәрүе рәвешендә яисә проектны конкрет сүзләр, пунктлар, өлешләр, статьялар һәм башка нигезләмәләр белән тулыландыру рәвешендә яки проектның конкрет нигезләмәләрен төшереп калдыру турындагы тәкъдимнәр рәвешендә язма рәвештә хокук чыгару инициативасы субъекты тарафыннан тиешле даими комиссиягә кертелә.

2. Норматив хокукый акт проектына төзәтмәләр тиешле даими комиссия утырышында каралырга тиеш, аның утырышы вакыты турында проектны керткән хокук чыгару инициативасы субъектына яисә аның вәкиленә хәбәр ителә. Төзәтмәләр таблицасы күрсәтелгән затларга комиссиядә каралганчы алдан, бер атнадан да соңга калмыйча җибәрелә.

4. Тиешле даими комиссия утырышында төзәтмәләрне караганда хокук чыгару инициативасы субъектлары яисә аларның вәкилләре тавыш бирү хокукы белән катнашырга хокуклы. Төзәтмәләр керткән хокук чыгару инициативасы субъекты яисә аның вәкиле комиссиядә фикер алышу барышында кертелгән төзәтмәләр редакциясен нигезләргә һәм төгәлләштерергә яисә аларны комиссиядән караудан төшереп калдырырга хокуклы.

5. Фикер алышу нәтиҗәләре буенча тиешле даими комиссия төзәтмә белән килешергә һәм аны норматив хокукый акт проекты текстына кертергә яки аны кире кагарга тәкъдим итәргә мөмкин.

6. Норматив хокукый акт проекты даими комиссия утырышында каралганнан соң, Район Советы тарафыннан икенче укылышта каралырга тиешле проектлар исемлегенә кертү өчен, кире кагуга тәкъдим ителгән төзәтмәләр таблицасы һәм комиссия тарафыннан хупланган төзәтмәләр таблицасы белән бергә Район Башлыгына җибәрелә.

**55 статья**

1. Район Советында норматив хокукый акт проектының икенче укылышы башында тиешле даими комиссиянең рәисе яисә вәкиле доклад белән чыгыш ясый.

2. Докладчы кергән төзәтмәләр, бәяләмәләр һәм аларны карап тикшерү нәтиҗәләре турында игълан итә.

3. Рәислек итүче Район Советы депутатларының яисә хокук чыгару инициативасының башка субъектларының яки аларның вәкилләренең тиешле комиссия тарафыннан хупланган һәм икенче укылышта карала торган проект текстына кертү өчен тәкъдим ителә торган төзәтмәләргә каршылыклары бармы-юкмы икәнлеген ачыклый. Каршылыклар булмаса, рәислек итүче тиешле даими комиссия тарафыннан хупланган төзәтмәләрне тулаем кабул итү турындагы

мәсьәләне тавышка куя. Хупланган һәм тиешле даими комиссия тарафыннан кабул итүгә тәкъдим ителгән төзәтмәләр арасыннан проект текстына кертүгә каршылыклар булса, рәислек итүче башта даими комиссия тарафыннан хупланган һәм каршылыклар булмаган төзәтмәләрне кабул итү турындагы мәсьәләне, аннары каршылыклары булган һәр төзәтмәне аерым тавышка куя. Төзәтмә авторы, тиешле даими комиссия вәкиле, шулай ук Район Советы депутаты яки хокук чыгару инициативасының башка субъекты яки аның каршылыклары булган вәкиле чыгышларында үз позицияләрен нигезли алалар. Шуннан соң тиешле төзәтмәне кабул итү турындагы мәсьәлә тавышка куела.

4. Әгәр проектның бер үк нигезләмәсенә берничә төзәтмә кертергә тәкъдим ителсә, башта аларны кабул итү яки кире кагу башка төзәтмәләр турындагы мәсьәләне хәл итәргә мөмкинлек бирәчәк темалар буенча булганнары турында фикер алышына һәм тавышка куела.

5. Төзәтмәләрне (төзәтмәләр) кабул итү турындагы карар Район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Әгәр тавыш бирү йомгаклары буенча мондый тәкъдим тиешле тавышлар санын җыймаса, төзәтмә өстәмә тавыш бирмичә генә кире кагылган дип санала.

6. Аннан соң Район Советы даими комиссия тарафыннан тәкъдим ителгән төзәтмәләрне карауга күчә. Рәислек итүче Район Советы депутатларының яки хокук чыгару инициативасының башка субъектларының яисә аларның Район Советы утырышында катнашучы вәкилләренең тиешле даими комиссия тәкъдимнәренә каршылыклары булу-булмавын ачыклый. Әгәр каршылыклар булмаса, кире кагу өчен тәкъдим ителгән барлык төзәтмәләр (әгәр каршылыклар булса - кире кагуга каршылыклар булмаган төзәтмәләр) кире кагу өчен тавышка куела. Төзәтмәләрне кире кагу турындагы карар Район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

7. Әгәр Район Советы төзәтмәләрнең кире кагылуы турында тиешле даими комиссия фикере белән килешсә, рәислек итүче төзәтмәләр авторларының кире кагуларына каршылыклар булган төзәтмәләрне тавышка куя. Төзәтмә авторы һәм даими комиссия вәкиле үз позицияләрен чыгышларда нигезли ала. Шуннан соң төзәтмәне кабул итү турындагы тәкъдим тавышка куела.

8. Әгәр даими комиссия тарафыннан кире кагу өчен тәкъдим ителә торган төзәтмәләр таблицасына тавыш биргәндә, Район Советы даими комиссия тәкъдиме белән килешмәсә, рәислек итүче төзәтмәләрнең һәркайсын аерым тавышка куя. Төзәтмә авторы һәм даими комиссия вәкиле үз позицияләрен чыгышларда нигезли ала. Шуннан соң төзәтмәне кабул итү турындагы тәкъдим тавышка куела.

9. Төзәтмәләр буенча тавыш бирү тәмамлангач, рәислек итүче норматив хокукый акт проектын тулаем кабул итү турындагы тәкъдимне тавышка куя. Район Советының норматив хокукый акты, әгәр аның өчен район Советы депутатларының күпчелеге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

10. Әгәр тавыш бирү нәтиҗәләре буенча проектны кабул итү турында тәкъдим тиешле тавышлар санын җыймаса, бу проект тиешле даими

комиссиягә эшләп бетерү өчен кире кайтарыла яисә Район Советы проектны кире кагу турында карар кабул итәргә мөмкин. Проектны эшләп бетерү өчен кире кайтарганда, Район Советы, икенче укылышта кабул ителгән төзәтмәләрне исәпкә алып, әлеге проектка кабат төзәтмәләр кертү өчен срок билгеләргә мөмкин.

11. Кирәк булганда, утырышта катнашкан депутатлар санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Район Советы карары буенча тулаем норматив хокукый акт проектын кабул итү турында тавыш бирү кичектерелергә мөмкин, ә проект Район Советы билгеләгән эчке юридик каршылыкларны бетерү, проект нигезләмәләренең үзара дөрес бәйләнешләрен билгеләү һәм лингвистик таләпләргә туры килүен билгеләү өчен тиешле даими комиссиягә җибәрелергә мөмкин.

12. Район Советы кабул иткән норматив хокукый актлар, Район Башлыгы кул куйган көннән соң 3 көннән дә соңга калмыйча, Район прокурорына җибәрелә.

**56 статья**

Район Советы тарафыннан Район бюджеты проектларын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны карау һәм раслау тәртибе Район Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

## 9 бүлек. Муниципаль район Уставы проектларын һәм муниципаль район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карарларны карау үзенчәлекләре

**57 статья**

1. Район Уставы проекты, Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Район Советы карары проекты Район Советына Район Башлыгы, Район Советы депутатлары, Район Башкарма комитеты Җитәкчесе, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, инициативалы төркем гражданнары тарафыннан кертелергә мөмкин.

2. Район Уставы проектларын карау яки Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар Район Советы утырышларында, әлеге Регламентта каралган тәртиптә, кимендә ике укылышта гамәлгә ашырыла.

3. Район Уставы проектын, Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар проектын әзерләү өчен, Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Район Советы карары белән махсус комиссия төзелергә мөмкин. Әлеге комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белгечләр, экспертлар чакырырга мөмкин.

4. Район уставы, Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар күпчелек тавыш белән район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан өчтән ике өлеше белән кабул ителә.

**58 статья**

Беренче укылышта кабул ителгән Район Уставы проекты, муниципаль район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы карар проекты, Район Уставын кабул итү турындагы мәсьәләне карап тикшереләсе көнгә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, бер үк вакытта әлеге Устав проекты, Район Советы тарафыннан билгеләнгән тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә, шулай ук аның турында фикер алышуларда гражданнарның катнашу тәртибе рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка игълан ителергә) тиеш.

**59 статья**

Район Уставы проекты, район Советының Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карары буенча Район Советы утырышының беренче укылышында карауга керткәнче ачык тыңлаулар үткәрелә.

**60 статья**

1. Устав проектларына төзәтмәләр һәм Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү һәркайсы аерым тикшерелә һәм тавышка куела. Төзәтмә Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе тавыш биргәндә кабул ителә.

2. Район Уставы проекты тексты яки Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү һәм булган юридик каршылыкларны бетерү турында карар проекты тикшерелгәннән соң Район Уставы проектын кабул итү яки Район Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Район Советы карары икенче укылышта Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе тавышы белән кабул ителә.

## 10 бүлек. Район Советы тарафыннан башка карарлар кабул итү тәртибе

**61 статья**

1. Район Советы Район Советы карарлары рәвешендә рәсмиләштерелә торган норматив булмаган актларны түбәндәге мәсьәләләр буенча кабул итә:

1) Район Башлыгын сайлау, Район Башлыгы урынбасарын сайлау һәм вазыйфасыннан азат итү, Район Советының даими һәм вакытлы комиссияләрен төзү, аларның рәисләрен сайлау һәм аларны вазыйфаларыннан азат итү турында;

2) Район Башкарма комитет Җитәкчесен билгеләү турында;

3) Районның чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору инициативасы күрсәтү, җирле референдум уздыру турында;

4) Районның чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору, җирле референдумны билгеләү мәсьәләләре буенча тавыш бирүне билгеләү турында;

5) Район Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс билгеләү турында;

6) җитәкче башкарма комитеты әгъзаларының комиссия конкурс өчен карау кандидатураларын биләү вазыйфасын биләү (алга таба - комиссия конкурсы);

7) Районның сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләү, җирле үзидарә органнарының башка вазыйфаи затларын билгеләү (сайлау, килештерү) турында;

8) ачык тыңлаулар билгеләү турында;

9) гражданнарны сораштыруны билгеләү турында;

10)муниципаль хокукый актлар проектларын һәм җирле әһәмияттәге башка аеруча мөһим мәсьәләләрне халык фикер алышуына чыгару турында;

11) Район Советының үз-үзен таркату, Район Советы депутатларының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында;

12) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы турында;

13) Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать турында;

14) прокурорның протестын (күрсәтмәләрен) карау турында;

15) процедура мәсьәләләреннән тыш, Район Советы карамагына кертелгән башка мәсьәләләр буенча.

2. Күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карар, әгәр дә закон белән башкасы билгеләнмәгән булса, Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелеге тавыш биргәндә кабул ителгән дип санала.

**62 статья**

1. Әлеге Регламентның 61 статьясында күрсәтелгән мәсьәләләрне Район Советы каравына кую инициативасы хокук чыгару инициативасы субъектларына, Район Уставында, әлеге Регламентта, законнарда каралган башка затларга, органнарга, оешмаларга карый.

2. Әлеге мәсьәләне Район Советы каравына чыгару инициаторы Район Советы карары проектын, шулай ук әлеге мәсьәләне карау өчен кирәкле һәм законнарда, Район Уставында, әлеге Регламентта, районның башка муниципаль хокукый актларында каралган башка документларны һәм материалларны тәкъдим итә.

3. Район Советы кадрлар мәсьәләләрен хәл иткәндә, шулай ук һәр кандидатка белешмә-объективка тапшырылырга, кандидатның тиешле вазыйфаны биләү өчен билгеләнгән таләпләргә туры килүен һәм бу вазыйфаны биләүгә комачаулаучы чикләүләр булмавын раслый торган документлар яисә аларның күчермәләре тапшырылырга тиеш.

**63 статья**

1. Әлеге Регламентның 61 статьясында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча карарлар, кагыйдә буларак, Район Советы тарафыннан, шушы мәсьәләләр буенча карар кабул итүнең башка срогы законнарда, Район Уставында яисә әлеге Регламентта каралмаган булса, аларны Район Советына керткән көннән алып бер ай эчендә кабул ителә.

2. Күрсәтелгән мәсьәләләр, кагыйдә буларак, Район Советы тарафыннан Район Советының тәкъдим ителә торган мәсьәлә аның карамагында булган даими комиссияләре тарафыннан алдан караганнан соң карала.

3. Күрсәтелгән мәсьәләләр буенча алынган материалларны теркәү, аларны алдан карау әлеге Регламентта билгеләнгән кагыйдәләр буенча Район Советының норматив хокукый актлары проектларын теркәү һәм алдан карау өчен гамәлгә ашырыла.

**64 статья**

Район Советының норматив булмаган характердагы карарлары проектлары, кадрлар мәсьәләләре, җирле референдум билгеләү, Районның чикләрен үзгәртү, үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү карарларыннан тыш, алар каралганчы, Район Советы тарафыннан халык тыңлауларына яисә халык фикер алышуларына чыгарылырга мөмкин. Районны үзгәртеп кору турындагы инициативаны күрсәтү турындагы карар проекты ачык тыңлауларга мәҗбүри рәвештә чыгарыла.

**65 статья**

Район Советының аерым норматив булмаган хокукый актлары проектлары аның утырышында катнашкан депутатлар санынnан күпчелек тавыш белән кабул ителгән карары буенча, Район Советының норматив хокукый актлары проектларын карауга карата әлеге Регламентта билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә ике укылышта карала.

## 11 бүлек. Район Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләп кую

**66 статья**

Башкарма комитет Җитәкчесе Район Советы тарафыннан әлеге вазыйфаны биләүгә конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан билгеләнә.

**67 статья**

1. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат белән конкурс комиссиясе рәисе чыгыш

ясый.

2. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасына һәр кандидат үз вәкаләтләре чорына алдагы эшчәнлекнең кыска программасы белән Район Советы утырышында чыгыш ясый.

3. Район Советы депутатлары конкурс комиссиясе рәисенә, кандидатларга сораулар бирергә, тәкъдим ителгән кандидатларга агитация ясарга хокуклы.

**68 статья**

1. Район Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләү мәсьәләсен, әгәр Район Советы тавыш бирүнең башка тәртибен билгеләмәсә, яшерен тавыш бирү юлы белән Район Советы хәл итә.

2. Район Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләп кую турындагы карар, әгәр аның өчен Район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелеге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала..

**69 статья**

1. Әгәр конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатларның берсе дә Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасына билгеләнү өчен кирәкле күләмдә депутатлар тавышы җыймаса, Район Советы Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кабат конкурс уздыру турында карар кабул итә.

2. Әлеге карарны кабул итү белән бер үк вакытта Район Советы Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс комиссиясенең элеккеге составында конкурс үткәрү турында яисә конкурс комиссиясенең яңа составын төзү турында карар кабул итә. Район Советы шулай ук конкурс комиссиясенең составының санын үзгәртү турында карар кабул итәргә мөмкин.

## 12 бүлек. Районның Контроль-хисап палатасы рәисен һәм аудиторларны сайлау һәм азат итү. Районның Финанс-бюджет палатасы рәисе, Районның Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе вазыйфасына билгеләү

**70 статья**

Районның Контроль-хисап палатасы рәисе үз вазыйфасына Район башлыгы тәкъдиме белән Район Советы тарафыннан сайлана һәм вазыйфасыннан азат ителә.

**71 статья**

Районның Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына сайлау яисә аны биләгән вазыйфасыннан азат итү турындагы карар Район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

**72 статья**

Районның Финанс-бюджет палатасы рәисе, Мөлкәт һәм жир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Район Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан Район Башлыгы белән килештереп билгеләнә.

**13 бүлек. Районның сайлау комиссиясе әгъзалары вәкаләтләрен билгеләү һәм вакытыннан алда туктату**

**73 статья**

1. Район сайлау комиссиясен төзү Район Советы тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашырыла.

2. Законнар таләпләрен исәпкә алып Районның сайлау комиссиясе составына кергән кандидатуралар буенча тәкъдимнәр, Район Советының профиль комиссиясенә һәр кандидатура һәм Район Советы карары проекты буенча бәяләмәне алдан карау һәм әзерләү өчен җибәрелә. Комиссия утырышында даими комиссия рәисе тарафыннан чакырылган кандидатлар һәм башка вазыйфаи затлар һәм гражданнар катнашырга хокуклы.

3.Законнар нигезендә билгеләнүе мәҗбүри булган Район сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләп кую турында карар кабул ителә.

4. Район сайлау комиссиясе әгъзаларының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы карар законнарда билгеләнгән очракта кабул ителә.

5. Муниципаль районның сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләп кую турындагы, аларның вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы карарлар Район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан шәхси тәртиптә күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм өстәмә тавыш бирүдән башка бер карар белән рәсмиләштерелә.

**14 бүлек. Район Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләү тәртибе**

**74 статья**

Конкурс комиссиясе әгъзалары Район Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатураларны карау өчен «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы нигезендә билгеләнә.

**75 статья**

1. Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санын билгеләү турында Район Советы карары Район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

2. Район Советы билгеләгән конкурс комиссиясе составына кандидатлар Район Башлыгы тарафыннан тәкъдим ителә.

3. Район Советының конкурс комиссиясе әгъзаларының өчтән ике өлешен билгеләү турындагы карары Район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләү турында тавыш бирү, кагыйдә буларак, һәр кандидатура буенча аерым гамәлгә ашырыла.

4. Конкурс комиссиясе әгъзаларын билгеләү Район Советының өстәмә тавыш бирүсез бер карары белән рәсмиләштерелә.

5. Тәкъдим ителгән кандидатура кире кагылган очракта, Район Башлыгы конкурс комиссиясе составына шул ук яисә яңа кандидатураны яңадан карау өчен тәкъдим итә.

## 15 бүлек. Район Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукларын гамәлгә ашыру

**76 статья**

Район Советы Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы хокукына ия.

**77 статья**

Район Советының закон чыгару инициативасы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелә.

**78 статья**

1. Закон чыгару инициативасы хокукын гамәлгә ашыру тәртибендә закон проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертү турындагы карар Район Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм тиешле карар белән өстәмә тавыш бирүдән башка рәсмиләштерелә.

2. Район Советы карарында Район Советы комитетларда һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында каралганда закон проектын

тәкъдим итүне йөкләгән зат күрсәтелә.

3. Кирәкле материаллар һәм Район Советы карары белән әзерләнгән закон проекты Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелә.

## 16 бүлек. Район Уставын һәм Район Советы карарларын аңлату

### 79 статья

Район Советы Район Уставына яки Район Советы карарларына Район Уставында яки Район Советы карарларында аңлашылмаучанлыклар булганда һәм аларның нормаларын төрлечә аңлап булганда, практикада куллануда каршылыклар ачыкланганда рәсми аңлатмалар бирә.

### 80 статья

Район Уставын яки Район Советы карарларын рәсми аңлату өчен хокук чыгару инициативасы субъектының тиешле мөрәҗәгате нигез булып тора.

### 81 статья

1. Район Уставын яки Район Советы карарларын аңлату турындагы мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча, тиешле даими комиссия Район Уставы яки Район Советы карары проектын әзерли һәм аларны Район Советы каравына кертә.

2. Район Уставын яки Район Советы карарын аңлату турындагы Район Советы карарлары тәңгәл рәвештә Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан өчтән икесенең тавышы һәм Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

## 17 бүлек. Прокурорның протестларын (күрсәтмәләрен) карау

### 82 статья

1. Район Советының хокукый актына прокурор протесты, шулай ук Район Советының закон бозуларны бетерү турындагы тәкъдиме район Советы тарафыннан алдагы утырышта мәҗбүри каралырга тиеш.

2. Утырыш көне турында протест (күрсәтмә) җибәргән прокурорга хәбәр ителә.

3.Протест турында фикер алышу протест җибәргән прокурорның яки аның вәкиленнән докладыннан һәм тиешле даими комиссиянең өстәмә докладыннан башлана.

4. Прокурор протесты нәтиҗәләре буенча Район Советы протест белән килешергә, протестны кире кагарга, белешмәләргә протест кабул итәргә һәм,

тәкъдимнәрне һәм кисәтүләрне исәпкә алып, аны карауны дәвам итәргә мөмкин.

5. Район Советының протест буенча карары прокурорга җибәрелә.

6. Прокурор күрсәтмәләре шундый ук тәртиптә карала.

7. Прокурор протесты белән килешкән очракта, Район Советы даими комиссиягә яисә Районның Башкарма комитетына Район Советының протестта күрсәтелгән кисәтүләрне юкка чыгаручы тиешле хокукый акты проектын әзерләргә куша.

## 18 бүлек. Район Советының контрольлек итү функцияләрен гамәлгә ашыруы

### 83 статья

1. Район Советы Район Уставының нигезләмәләрен, Район Советы тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актларның үтәлешен, Район бюджетының үтәлешен, бюджеттан тыш фондлар чаралары үтәлешен, Район үсеше планнарын һәм программаларын, Район Башкарма комитеты һәм аның Җитәкчесе эшчәнлеген контрольдә тота.

2. Районның җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан закон, Район Уставы һәм башка муниципаль хокукый актлар бозылу фактлары ачыкланган очракта, Район Башлыгы, депутатларның билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә торган Район Советы карары белән депутатлар арасыннан әлеге фактларны тикшерү өчен вакытлы контрольлек итү комиссиясе төзелергә мөмкин.

### 84 статья

1. Район Советының һәр карарында, кагыйдә буларак, аның үтәлешен тикшереп тору йөкләнгән даими комиссия яисә Район Советы депутаты күрсәтелә.

2. Контрольнең максаты булып хокукый актның нәтиҗәлелеге дәрәҗәсен, аны башкаруны кыенлаштыра торган сәбәпләрне, аларны үтәүгә комачаулаучы затларны җаваплылыкка тарту, шулай ук аны зарурлык булганда судта яклау тора.

3. Хокукый актның эш кушу пунктында башкаручы зат һәм, кагыйдә буларак, башкару вакыты күрсәтелә. Даими комиссия яки контрольлек итү йөкләнгән депутат хокукый актны үтәү барышы турында үз вакытында хәбәр әзерләргә тиеш.

4. Әлеге хәбәрне тыңлаганнан соң Район Советы түбәндәгеләргә хокуклы:

1) хокукый актны башкарылган итеп контрольдән төшерергә;

2) контрольлек вәкаләтләрен озайтырга;

3) контрольлек вәкаләтләрен башка комитетка яисә депутатка йөкләргә;

4) хокукый актны гамәлдән чыгарырга;

5) хокукый актны үзгәртергә яисә тулыландырырга.

5. Контрольлек итү буенча хисап чоры хокукый актта яисә беркетмә карарында билгеләнә.

**85 статья**

1. Район Башкарма комитеты Җитәкчесе елга бер тапкырдан да ким булмаган санда Район Башлыгы, депутатларның билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителгән Район Совет таләбе буенча Район Советына Район Башкарма комитетының эшчәнлеге һәм үз эшчәнлеге турында хисап бирә.

2. Район Советы утырышында Район Башкарма комитеты Җитәкчесе яки аның урынбасары хисап белән чыгыш ясый.

3. Фикер алышу йомгаклары буенча Район Советы карар кабул итә.

**86 статья**

Районның Башкарма комитеты, аның Җитәкчесе, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, вазыйфаи затлар, әгәр закон белән башкасы билгеләнмәгән булса, Район Советы, аның контроль комиссияләре, депутаты Район Советы соратулары буенча Район Советы карамагындагы мәсьәләләр буенча мәгълүмат бирергә, ә законнар, муниципаль хокукый актлар бозу күрсәтелгән очракта, хокук бозуларны бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту өчен кичекмәстән чаралар күрергә тиеш.

**87 статья**

1. Район Советының президиумы, даими комиссияләре җирле үзидарәнең вазыйфаи затларын тыңларга, Район Советы карамагындагы мәсьәләләр буенча кирәкле документларны һәм материалларны таләп итәргә хокуклы.

2. Җирле үзидарәнең вазыйфаи затларын тыңлау йомгаклары буенча президиум, даими комиссия карар кабул итә.

## Глава 19. Йомгаклау нигезләмәләре

**88 статья**

1. Әлеге Регламентка үзгәрешләр һәм өстәмәләр Район Советы тарафыннан Район Советы депутатларының билгеләнгән санынннан күпчелек тавыш белән кабул ителә.

2. Әлеге Регламентка үзгәрешләр һәм өстәмәләр карау һәм кабул итү әлеге Регламентның 8 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.